2. Район икътисадындагы, шул исәптән икътисадның билгеле бер тармакларындагы (идарә өлкәләрендәге) структур үзгәрешләргә хосусыйлаштыруның йогынтысы фаразы.

Гомумән алганда, 2024 елга Арча районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планында (программасында) күрсәтелгән мөлкәт объектларын хосусыйлаштыру район икътисады, шул исәптән икътисадның билгеле бер тармагындагы (идарә өлкәләрендәге) структур үзгәрешләргә йогынты ясамаячак.

3. Арча муниципаль районы бюджетына муниципаль мөлкәтне сатудан акча керү фаразы.

Арча районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) нигезендә 2024 елга 7 күчемсез һәм 6 күчемле мөлкәтне хосусыйлаштыру күздә тотыла.

Күчемсез һәм күчемле муниципаль мөлкәт объектларын хосусыйлаштырудан Арча муниципаль районы бюджетына планлаштырылган кертемнәр 1 500,00 мең сумнан да ким булмаячак.

## II бүлек. 2024 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль мөлкәт исемлеге

| № т/б | Мөлкәтнең исеме һәм урнашкан урыны | Характеристикасы |
|---|---|---|
| 1 | Венета ав., Үзәк ур., 13 йорт адресы буенча урнашкан административ бина һәм җир кишәрлеге | 57,5 кв. м мәйданлы, бер катлы |
| 2 | Сикертән ав., Мәктәп ур., 79 йорт адресы буенча урнашкан котельный бинасы, административ бина һәм җир кишәрлеге | Административ бина - 120,1 кв.м мәйданлы, бер катлы; котельный бинасы - 16.1 кв.м. мәйданлы, бер катлы |
| 3 | Арча шәһәре, Совет мәйданы, 10 йорт (объект мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән) адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге булган торак булмаган бина (РФ Үзәк банкы бинасы) | 461,7 кв.м. мәйданлы, өч катлы, шул исәптән 1 җир асты каты |
| 4 | Кушлавыч ав., Тукай ур., 62 йорт адресы буенча урнашкан китапханә бинасы һәм җир кишәрлеге | 85,1 кв. м мәйданлы, бер катлы |

| | | |
|---|---|---|
| 5 | Lada SAMARA 211440 маркалы автомобиль (А550 СМ 716RUS дәүләт номерлы) | 2011 елда чыгарылган, соры-яшел металлик төсендә |
| 6 | FIAT ALBEO (К790КТ 716 RUS дәүләт номерлы) | 2011 елда чыгарылган, соры хроно төсендә |
| 7 | CHEVROLET NIVA (А 730 КМ 716 RUS дәүләт номерлы) | 2017 елда чыгарылган, куе соры металлик төсендә |
| 8 | FIAT DUCATO (В990 ОТ 116 дәүләт номерлы) | 2010 елда чыгарылган, ак төстә |
| 9 | CHEVROLET NIVA (У 365 РУ 116 RUS дәүләт номерлы) | 2014 елда чыгарылган, куе соры металлик төсендә |
| 10 | CHEVROLET NIVA (У 449 ВА 116 RUS дәүләт номерлы) | 2014 елда чыгарылган, ачык металлик төсендә |
| 11 | Ford Explorer (2014 елда чыгарылган) | 2014 елда чыгарылган, ак төстә |
| 12 | Арча муниципаль районы, Шурабаш ав,, Гагарин ур., 17 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге белән административ бина | 230,5 кв. метр мәйданлы, бер катлы |
| 13 | Арча муниципаль районы, Кече Төрнәле ав,, Г. Тукай ур., 14 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге белән башлангыч мәктәп бинасы һәм котельный бинасы | бина –49,3 кв.м. мәйданлы, бер катлы; котельный бинасы –9.9 кв.м. мәйданлы, бер катлы |